**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**10 нчы сыйныф**

**Максималь балл –63**

**I. ТЕСТ (20 балл)**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **4** | **4** | **3** | **1** | **3** | **1** | **2** | **2** | **өтер** | **үз** |

**II. Теоретик бирем.**
Татар теленең орфографик принциплары турында языгыз, мисаллар китерегез. **(8 балл)**
Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны кимetelә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

**III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.**
Синоним сүзләрне үзара тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) шыту | 1) җай |
| Б) тойгы | 2) гамьсез |
| В) форсат | 3) җан |
| Г) кот | 4) хис |
| Д) ваемсыз | 5) тишелү |

**Җавап : 54132**

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**
1. Бирелгән сүзләрнең тамырын языгыз. **(5 балл)**
Җәмәгатьчелек –**җәмәгать**
Сырганак –**сыр(у)**
Караңгы –**кара**
Тартма –**тарт(у)**
Аңлаешлы –**аң**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(1 балл) һәр җавапка – 0,5 балл**

Нигә диеп мин аңлатыйм икән
Шушы сәер, иләс чагымны?
Хәреф төртсәң, шигыр**ь** үсеп чыгар -
Шундый чагы әле җанымның...
Вето салдым барлык мескенлеккә!
Җитте! Оят ап-ак бол**ы**ттан!
Яшәү дигән тантанага бит без
Вакытлыча гына юлыккан... (*Зөлфәт*)

3. *Вето* сүзенең татар телендә кулланыла торган ике синонимын языгыз. **(2 балл)**
**тыю, рөхсәт итмәү, тоткарлау ....**
4. *Иләс* сүзенең мәгънәсен аңлатып языгыз. (**3 балл)**
**Иләс – ашкынучан, җилкенүчән, шашкын, ярсулы.**
5. *Мескенлеккә* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл)**
Мескен – тамыр, -лек – исем ясагыч кушымча, -кә – бәйләгеч, юнәлеш килеше кушымчасы.
Мескенлеккә (салдым) – ясалма, уртаклык исем, юнәлеш килешендә, берлек санда, тартымсыз.

6. Шигырьдәге *юлыккан* сүзенең транскрипциясен языгыз, фонетик анализ ясагыз. **(2 балл)**
[йулыққан]
7 хәреф, 8 аваз. 3 иҗектән тора. Сузык авазлар: [у], [ы], [а]. Тартык авазлар: [й], [л], [к], [к], [н].
[у] – арткы рәт, югары күтәрелешле, иренләшкән озын сузык аваз.
[ы] - арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән кыска сузык.
[а'] – арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән озын сузык аваз.
й] – сонор, парсыз, тел уртасы, өрелмәле, авыз тартыгы.
[л] - сонор, парсыз, тел алды (тел-теш), ярымйомык, авыз тартыгы.
[к] – кече тел, йомык, парлы, саңгырау тартык.
[н] – сонор, парсыз,тел алды яңгырау тартык .
7. Шигырьдән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны күчереп языгыз. **(2 балл)**
**ап-ак**

8.“ *Игелекле эш*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)